Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге

# КАРАР

2023 елның 29 август, № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске- Йорт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске- Йорт авылында гражданнар Җыенының 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы мәсьәлә буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Иске-Йорт авылында халык җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске- Йорт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Иске Йорт авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:
8 нче пункт белән тулыландырырга:
«8. Янгын гидрантларын һәм комплектлау материалларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә: Җыенда сайлау хокукына ия булучылар 123 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 63 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 70 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Иске-Йорт авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре-гамәлдә, дип танырга.

2. «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Иске-Йорт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында " 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Иске Йорт авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:
8 нче пункт белән тулыландырырга:
«8. Янгын гидрантларын һәм комплектлау материалларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү»

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән

3. Җыенның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев